КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 ноябрь г.Казань № 877

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары белән расланган Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 февраль, 81 нче; 2017 ел, 21 март, 173 нче; 2017 ел, 16 август, 585 нче; 2017 ел, 1 сентябрь, 626 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның бишенче, алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының эре предприятиеләре буенча югары һәм урта һөнәр белеме бирүнең мәгариф программалары буенча әзерләүгә тармак ихтыяҗын

фаразлауны формалаштырганда, тармак министрлыклары, ведомстволар яңа мәгариф программаларын ачу перспективаларын исәпкә алу өлешендә Татарстан Республикасы предприятиеләрендә югары белем бирүче белем оешмаларының база кафедралары белән үзара хезмәттәшлек итә.

Тармак министрлыклары, ведомстволар планлаштырыла торган елдан соң килә торган 7 елга югары һәм урта һөнәр белеме бирү программалары, планлаштырыла торган елга кадрларны тизләтеп әзерләү программалары буенча квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә ихтыяҗ турындагы мәгълүматларны Бюджет учреждениеләре эшчәнлеге мониторингы мәгълүмат-аналитика системасының автоматлаштырылган системасы ярдәмендә кертүне гамәлгә ашыра. Мәгълүматларны керткәндә һөнәрләр һәм белгечлекләр кодлары югары һәм урта һөнәр белеме бирү программалары буенча – Россия Федерациясе Стандартлаштыру һәм метрология буенча дәүләт комитетының гамәлдәге норматив актлары нигезендә (ОК 009-2016 нчы мәгариф буенча белгечлекләрнең гомумроссия классификаторы), кадрларны тизләтеп әзерләү программалары буенча Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Һөнәр белеме бирү гамәлгә ашырыла торган эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 ел, 2 июль, 513 нче боерыгы белән расланган Һөнәр белеме бирү гамәлгә ашырыла торган эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге нигезендә күрсәтелә.»

4 нче пунктның – җиденче, 6 нчы пунктның алтынчы абзацларындагы «БАРС WEB Бюджет учреждениеләре эшчәнлеге мониторингы мәгълүмат-аналитика системасы» дигән сүзләрне «Бюджет учреждениеләре эшчәнлеге мониторингы мәгълүмат-аналитика системасы» дигән сүзләргә алыштырырга.

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\877.docx